Педагогик киңәшмәдә кабул ителде
Протокол № 1
«31» 08 2021 ел

Раслыйм
«Актаныш гомуми үсеш бирүче №4 балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе
мөдире ________ Аглямова М.В.
№ ______ приказ нигезендә гамәлгә керде
31 август 2021 ел

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«АКТАНЫШ ГОМУМИ ҮСЕШ БИРҮЧЕ №4 БАЛАЛАР БАКЧАСЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕНЕҢ

# 2021-2022 НЧЕ УКУ ЕЛЫНА ЭШ ПЛАНЫ

# ГОДОВОЙ ПЛАН РАБОТЫ НА 2021-2022 УЧЕБНЫЙ ГОД

МУНИЦИПАЛЬНОГО БЮДЖЕТНОГО ДОШКОЛЬНОГО ОБРАЗОВАТЕЛЬНОГО УЧРЕЖДЕНИЯ
«ДЕТСКИЙ САД ОБЩЕРАЗВИВАЮЩЕГО ВИДА №4 С. АКТАНЫШ»
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Актаныш, 2021 ел

**Эчтәлек**

**I ИНФОРМАЦИОН БҮЛЕК**

1.1 Балалар бакчасы турында гомуми мәгълүмат........................................................ 3

1.2 “Актаныш гомуми үсеш бирүче 4нче балалар бакчасы” мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең 2021-2022 нче уку елы эшчәнлегенә анализ........................................................................................................................ 4

**II ЭШ ПЛАНЫ**

2.1 Яңа 2021-2022 уку елына куелган бурычлар, проблемалар һәм перспективалар

2.1.1 Максат, бурычлар................................................................................................ 20

2.1.2 Педагогик кадрлар.............................................................................................. 21

2.1.3 Белем дәрәҗәсен һәм педагогик квалификацияне күтәрү ........................ 22

2.1.4 Педагогларның аттестациясе............................................................................ 24

2.1.5 Педагогларның компетенциясен күтәрү графигы....................................... 25

2.2 Педагогик кадрлар белән эшне оештыру.......................................................... 25

2.2.1 Педагогик киңәшмәләр...................................................................................... 25

2.2.2 Семинарлар ........................................................................................................ 27

2.2.3 Консультацияләр, мастер-класслар................................................................ 27

2.2.4 Ачык чаралар...................................................................................................... 28

2.2.5 Күргәзмәләр, акцияләр...................................................................................... 29

2.2.6 Конкурслар.......................................................................................................... 29

2.2.7 Тематик атналыклар, көннәр........................................................................... 30

2.2.8 Сәламәтләндерү һәм профилактик чаралар................................................ 31

2.2.9 Тәрбия һәм белем бирү эшенә контроль....................................................... 31

2.2.10 Алдынгы тәҗрибәне өйрәнү, гомумиләштерү, тарату..............................35

2.2.11 Методик бүлмәне җиһазлау һәм тулыландыру.........................................35

2.2.12 Бәйрәмнәр, күңел ачулар.................................................................................36

2.3 Ата-аналар һәм җәмәгатьчелек белән эш..........................................................37

2.3.1 Гомуми ата-аналар җыелышы...........................................................................37

2.3.2 Төркемнәрдә ата-аналар җыелышы.................................................................38

2.3.3 Ата-аналар өчен консультацияләр....................................................................39

2.3.4 Ачык ишекләр көне.............................................................................................41

2.3.5 Җәмәгатьчелек белән эш....................................................................................41

2.4 Административ эш................................................................................................42

2.4.1 Балаларның һәм хезмәткәрләрнең иминлеген саклау...................................42

2.4.2 Туклануны оештыру............................................................................................43

2.4.3 Администрациянең оператив киңәшмәләре....................................................43

2.4.5 Профсоюз комитетының эш планы..................................................................43

## I ИНФОРМАЦИОН БҮЛЕК

### 1.1 Балалар бакчасы турында гомуми мәгълүмат

| | |
|---|---|
| **Балалар бакчасының тулы исеме** | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы "Актаныш гомуми үсеш бирүче 4нче балалар бакчасы" мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе |
| **Юридик адресы, телефоны** | 423740, ТР, Актаныш муниципаль районы,<br>Актаныш авылы, Ленин пр., 65б.<br>Телефоны: 8 (85552) 3-19-28 |
| **Электрон почта адресы** | **detsad-4@mail.ru** |
| **Рәсми сайты адресы** | "Электронное образование Республики Татарстан" порталында рәсми сайты:<br>**https://edu.tatar.ru/aktanysh/dou4** |
| **Эш режимы** | Атнага 5 көн 10,5 сәг.: 7.00.сәг. 17.30 сәг. кадәр.<br>Шимбә, якшәмбе һәм бәйрәм көннәр - ял көннәре. |
| **Файдалануга тапшырыл-ган вакыты** | 1984 ел, август<br>Балалар бакчасы типовой проект буенча эшләнгән ике катлы кирпеч бинада урнашкан. Җылылык, су белән тәэ-мин итү һәм канализация системалары үзәкләштерелгән. |
| **Документ-лары** | ➢ Лицензия (сериясе 16 Л 01 №0004844, 14.10.2016 елдан теркәлү №8829),<br>➢ Свидетельство о внесении в ЕГРЮЛ (сериясе 16 №006393440, 2012 елның 11.01. теркәлгән),<br>➢ Устав (2015 елның 21.10. теркәлгән, распоряжение № 12-р). |
| **Балалар бакчасы төре** | Гомуми үсеш бирүче.<br>Барысы гомуми үсеш бирүче төрдәге 6 төркем эшли.<br>Милләтләре буенча күпчелек бала татарлар. Тәрбия һәм белем бирү татар телендә алып барыла. |
| **Мөдир** | Аглямова Миләүшә Васил кызы, белеме – югары, эш стажы - 4 ел, бу вазыйфада – 1 ел. |
| **Педагогик кадрлар** | Өлкән тәрбияче – 1,<br>Музыка җитәкчесе -1,<br>Физкультура инструкторы – 1,<br>Рус теле тәрбиячесе – 1,<br>Укытучы-логопед - 1,<br>Педагог-психолог - 1,<br>Инглиз теле тәрбиячесе – 1,<br>Тәрбиячеләр – 8. |

## 1.2 “Актаныш гомуми үсеш бирүче 4нче балалар бакчасы” мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең 2020 - 2021 нче уку елында эшчәнлегенә анализ

## Гомуми мәгълүмат

Актаныш муниципаль районы “Актаныш гомуми үсеш бирүче 4 нче балалар бакчасы” мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесендә 2020-21 нче уку елында барысы 6 төркемдә (шулардан 2се – иң кечкенәләр, 4се – мәктәпкәчә төркемнәрдә) 140 бала тәрбияләнде. Шулардан

| | | |
|---|---|---|
| Ясле төркеме | 1 яшьтән 2 яшькә кадәр | 16 бала |
| 1 кечкенәләр төркеме | 2 яшьтән 3 яшькә кадәр | 22 бала |
| 2 кечкенәләр төркеме | 3 яшьтән 4 яшькә кадәр | 25 бала |
| Уртанчылар төркеме | 4 яшьтән 5 яшькә кадәр | 25 бала |
| Зурлар төркеме | 5 яшьтән 6 яшькә кадәр | 26 бала |
| Мәктәпкә әзерлек төркеме | 6 яшьтән 7 яшькә кадәр | 26 бала |

26 бала мәктәпкә әзерлек төркеменнән, 2 бала зурлар төркеменнән мәктәпкә озатылды.

### Педагогларның һәм балаларның районкүләм һәм республикакүләм үткәрелгән конкурсларда катнашу нәтиҗәләре

***Педагоглар***

| № | Конкурс исеме | ФИО | Уровень | Нәтиҗә | Балл |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Тат конкурс “Знатоки дороги” | Арсланова Г.М. | республика | 1 место | 10 |
| | | Габдрахманова Э.Р. | | 1 место | 10 |
| | | Шаяхметова Г.Ф. | | 2 место | 8 |
| | | Бадертдинова И. | | 2 место | 8 |
| | | Ибнеева Р.Р. | | 2 место | 8 |
| 2 | “Дорога без опасности”, ковробук | Габдрахманова Э. | всеросийский | участник | 1 |
| 3 | «Лучший тематический альбом, приуроченный к 100-летию образования ТАССР» | Бадертдинова И. | район | 2 место | 4 |
| | | Ганиева Э. | | 3 место | 3 |
| | | Набиева Ч. | | 3 место | 3 |
| | | Мансурова Э. | | 3 место | 3 |
| | | Габдрахманова Э. | | Номинация | 2 |
| 4 | “Дорога БЕЗ опасности” | Арсланова Г.М. | район | 2 место | 4 |
| | | Ганиева Э.И. | | участник | 1 |
| | | Шаяхметова Г.Ф. | | 2 место | 4 |
| | | Габдрахманова Э.Р. | | 1 место | 5 |
| 5 | Конкурс грантов имени Выготского | Бадертдинова И.Р. | всероссийский | участник | 4 |
| | | Арсланова А.М. | всероссийский | участник | 4 |
| 6 | «В мире игр» | Габдрахманова Э. | район | 1 место | 5 |
| | | Садыкова Р.Р. | | 2 место | 4 |
| | | Мансурова Э. | | 1 место | 5 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Арсланова Г.М. | | 1 место | 5 |
| | | Бадертдинова И. | | 1 место | 5 |
| | | Ардуанова Г. | | 1 место | 5 |
| | | Набиева Ч. | | 1 место | 5 |
| | | Ганиева Э. | | 2 место | 4 |
| | | Ибнеева Р. | | 1 место | 5 |
| 7 | "Народы разные – Республика одна!" | Арсланова Г.М. | Республика | 1 место | 10 |
| | | Бадертдинова И.Р. | | 1 место | 10 |
| 8 | Конкурс авторских разработок и авторских игр. г.Азнакаево | Арсланова Г.М. | Республика | участник | 4 |
| 9 | Республиканского конкурса методических разработок «Практическая реализация ФГОС в образовательной организации: урок и непосредственная образовательная деятельность» | Бадертдинова И.Р. | Республика | лауреат | 4 |
| 10 | «Лучшая методическая разработка» IV Всероссийский конкурс профессионального мастерства | Бадертдинова И.Р. | всероссийский | 1 степень | 10 |
| 11 | Всероссийская олимпиада «Педагогический успех» в номинации: Музыкальное воспитание дошкольников | Бадертдинова И.Р. | всероссийский | 1 место | 10 |
| 12 | «Ученый малыш» | Ардуанова Г.Т. | | диплом | 5 |
| | | Ганиева Э.И. | | диплом | 5 |
| | | Садыкова Р.Р. | | диплом | 5 |
| | | Шакурова Г.Ф. | | диплом | 5 |
| 13 | «Юный эрудит» | Ганиева Э.И. | | Диплом педагога. Приказ от 25.02.2020 №14-1 | 5 |
| | | Ганиева Э.И. | | Диплом педагога. Приказ от 19.04.2021 №38-09 | 5 |
| 14 | «Воспитатель года – 2021» | Бадертдинова И.Р. | район | 2 место | 4 |
| | | | зональный | участие | 2 |
| 15 | «Татар сүзе» | Ардуанова Г.Т. | республика | Рәхмәт хаты | 5 |
| | | Ганиева Э.И. | | Рәхмәт хаты | 5 |
| | | Арсланова Г.М. | | Рәхмәт хаты | 5 |
| | | Мансурова Э.Р. | | Рәхмәт хаты | 5 |
| | | Шаяхметова Г.Ф. | | Рәхмәт хаты | 5 |
| | | Садыкова Р.Р. | | Рәхмәт хаты | 5 |
| | | Габдрахманова Э.Р. | | Рәхмәт хаты | 5 |
| | | Ибнеева Р.Р. | | Рәхмәт хаты | 5 |
| | | Шакурова Г.Ф. | | Рәхмәт хаты | 5 |
| 16 | «Кросс наций» | Сарварова А.Э. | район | 1 место | 5 |
| | | Зиннурова Р. | район | 2 место | 4 |
| 17 | «Лыжня Росии» | Бахтиева Г. | район | 2 место | 4 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 18 | «Диалог культур» | Арсланова Г.М. | Республика | Диплом | 5 |
| | | Ганиева Э.И. | | Диплом | 5 |
| **Гомуми нәтиҗә: 277** | | | | | |
| **Балалар бакчасы коллективы** | | | | | |
| 1 | Татарстанда туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган смотр-конкурс | | район | 3 место | 3 |
| 2 | “Лучший билигвальный детский сад” | | Республика | участник | 4 |
| 3 | “Кыш бабай һәм экият персонажлары” парады | | район | 1 место | 5 |
| 4 | Спонсирование «Гранат Стан групп» | | республика | | 10 |
| 5 | «Сбор отработанных батареек» | | район | 2 место | 4 |
| **Гомуми нәтиҗә: 26** | | | | | |
| **Балалар** | | | | | |
| 1 | “Созвездие-2021” | | район | 2 место | 4 |
| 2 | «Лыжня России» | Аминова Камиля | район | 2 место | 4 |
| | | Газетдинова Данил | | 3 урын | 3 |
| 3 | “Говорим и поём по-английский” | Мокимова Рената, вокал-соло | район | 1 место | 5 |
| | | Вокаль ансамбль | | 3 место | 3 |
| 4 | Республиканский дистанционный конкурс-фестиваль творчества на английском языке | Вокаль ансамбль | Республика | Диплом | 4 |
| | | Вокаль ансамбль | | Диплом | 4 |
| | | Мокимова Рената | | Диплом | 4 |
| 5 | II Республиканские Джалиловские чтения | Шаймурзина Алина | район | 2 место | 4 |
| | | Мокимова Рената | район | 3 место | 3 |
| 6 | «Буду бдительным на льду ина воде» в номинации «Рисунок» | Анваров Тамерлан | Район | 2 место | 4 |
| 7 | «Татар сүзе» | Зиннурова Аделина | Республика | Рәхмәт хаты | 5 |
| | | Шаймурзина Алина | | Рәхмәт хаты | 5 |
| | | Вахитова Раяна | | Рәхмәт хаты | 5 |
| | | Софиянов Амир | | Рәхмәт хаты | 5 |
| | | Вильданова Алсу | | Рәхмәт хаты | 5 |
| | | Сабирова Зиля | | Рәхмәт хаты | 5 |
| | | Ханипова Алиана | | Рәхмәт хаты | 5 |
| | | Галиева Эльвина | | Рәхмәт хаты | 5 |
| 8 | Олимпиада “Ученый малыш” | Тимеров Адель | Республика | 1 место | 10 |
| | | Шаймиева Эльза | | 2 место | 8 |
| | | Мокимова Рената | | 1 место | 10 |
| | | Басыров Раяз | | 1 место | 10 |
| | | Зиннурова Аделина | | 1 место | 10 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Бадертдинова Иделия | | 1 место | 10 |
| | | Вильданова Алсу | | 1 место | 10 |
| | | Амирханова Альбина | | 1 место | 10 |
| | | Аминова Камиля | | 1 место | 10 |
| | | Вакилов Эльвир | | 1 место | 10 |
| | | Гафуров Зиннур | | 2 место | 8 |
| | | Карамов Максим | | 1 место | 10 |
| | | Ханипова Алиана | | 1 место | 10 |
| 9 | Олимпиада «Юный эрудит» | Вакилов Эльвир | Республика | 2 место | 8 |
| | | Сабирова Зиля | | 2 место | 8 |
| | | Вильданова Алсу | 12.09.2020 | 3 место | 6 |
| | | Вильданова Алсу | 27-28 марта 2021 | 2 место | 8 |
| 10 | Конкурс творческих работ «Рабочей профессией славится мой Татарстан!», посвященный 100-летию образования ТАССР» | Агумов Ибрахим Гафуров Зиннур | Республика | участник | 4 |
| | | Галиев Рияз Низамов Амирхан | | 1 место | 10 |
| 11 | Конкурс ко дню матери «Мама – солнышко мое» | Тагирова Ясмин | Республика | участник | 4 |
| 12 | «Елочка – зеленая иголочка» | Ахметова Арина | Республика | участник | 4 |
| | | Вильданова Алсу | | участник | 4 |
| 13 | «Шушы яктан – шушы туфрактан без» | Ахметова Арина | Район | номинация | 2 |
| | | Шаемова Р. | | участник | 1 |
| | | Амирханова А. | | участник | 1 |
| | | Зиннурова Аделина | | участник | 1 |
| | | Шаймурзина Алина | | участник | 1 |
| 14 | Конкурс рисунков «По произведениям Г.Тукая» | Ахметова Арина | Район | участник | 1 |
| | | Вакилов Эльвир | | участник | 1 |
| 15 | «Новый дорожный знак глазами детей» | Анваров Тамерлан | всероссийский | 1 место | 10 |
| | | Сабирова Зиля | | 3 место | 6 |
| 16 | «Зимние фантазии» | Гафуров Ригель | региональный | 3 место | 6 |
| 17 | «Театр и дети» | Творческий коллектив | район | 3 место | 3 |
| | | | | | **Гомуми нәтиҗә: 297** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Прошло РМО руководителей ДОУ | район | **5** |
| | | | **Гомуми нәтиҗә: 5** |

Педагогик кадрларның эшчәнлегеннән күренгәнчә, педагоглар бала шәхесенә якын килеп эшлиләр, балалар бакчасындагы эшчәнлектә актив катнашалар, ләкин үзләренең эш тәҗрибәләрен район, республика югарылыгында күрсәтү, тарату тәҗрибәсе җитми. Моның өчен махсус белем күтәрү курсларына бару кирәк (юл хәрәкәте иминлеге буенча, “Ел тәрбиячесе” конкурсында катнашучылар өчен). Балалар белән эшчәнлектә ФДББС таләпләрен тормышка ашыру өчен аерым педагогларга үз белемнәрен һәм осталыкларын күтәрү, заманча уңышлы технологияләрне куллану өстендә эшләү зарур.

Милләтләре буенча күпчелек бала татарлар, тәрбия һәм белем бирү дә татар телендә, “Гомуми үсеш бирүче №4 балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең белем бирү программасы нигезендә оештырылды. Белем бирү программасында кулланыла торган программалар һәм укыту-методик комплектлар:

- «От рождения до школы» под ред. Вераксы Н.Е., Комаровой Т.С., Васильевой М.А., Москва «Мозаика-Синетез», 2014.
- Региональная программа дошкольного образования, Шаехова Р.К., Казан, 2012.
- Гафарова С.М., Гарафиева Г.З. Изучаем русский язык (укыту-методик ком-плекты), Казан «Хәтер», 2011,
- Туган телдә сөйләшәбез (2-3 яшь) (укыту-методик комплекты), Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибуллина И.Җ., Казан Татарстан китап нәшрияте, 2012 .
- Туган телдә сөйләшәбез (3-4 яшь) (укыту-методик комплекты), Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибуллина И.Җ., Казан «Фолиант», 2013.
- Туган телдә сөйләшәбез (4-5 яшь) (укыту-методик комплекты), Хазратова Ф.В., Шарафетдинова З.Г., Хабибуллина И.З., Казан «Инновацион техноло-гияләр үзәге», 2013.
- Туган телдә сөйләшәбез (5-7 яшь) (укыту-методик комплекты), Зарипова З.М., Вәҗиева Л.Н., Зөфәрова Р.С., Казан «Фолиант», 2012.
- Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларны юлларда үз-үзеңне хәвефсез тоту кагыйдәләренә өйрәтү (Тематик планнар һәм программалар) Россия белем академиясенең Идел буе бүлеге балалар тормышы куркынычсызлыгы фонды, Казан, 1997.
- Гаилә һәм балалар бакчаларында әдәплелек тәрбияләү программасы, Закирова К.В.
- «Раз-ступенька, два-ступенька...» курса математики для детей 5-7 лет, Л.Г.Петерсон, Е.Е.Кочемасова (по программе «Школа – 2000..»)

**Балалар бакчасының материаль-техник торышы**

Балалар бакчасының территориясе яшеллеккә күмелеп утыра: территория юкә агачлары белән әйләндереп алынган, бакча территориясендә кызыл миләш, чыршы, усак агачлары, бакчасында җимеш агачлары һәм куаклары: алма, груша, чия, слива үсә, яшелчә түтәлләре бар. Чәчәклекләр, балалар өчен яшелчәләр бакчасы, дару үләннәре почмагы, басу культуралары почмагы, эшләнгән. Балалар бакчасында балаларга белем һәм тәрбия бирү, аларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен шартлар да булдырылган.

Балалар бакчасында:

- 6 төркем бүлмәләре
- физкультура-музыка залы
- методик бүлмә
- рус теленә өйрәтү бүлмәсе
- логопункт
- юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү бүлмәсе

- медицина бүлмәсе
- физиодәвалау бүлмәсе бар.

Һәр бүлмәдә кирәкле җиһазлар, оборудование, күрсәтмә һәм дидактик материаллар булдырылган.

Шулай ук саф һавада физик үсеш эшчәнлекләрен үткәрү өчен физкультура мәйданчыгы, 6 уен мәйданчыгы балалар белән хәрәкәтле һәм тыныч уеннар, сюжетлы-рольле уеннар, ком һәм су белән уеннар өчен җиһазландырылган.

**Педагогик кадрлар**

Балалар бакчасы педагогик кадрлар белән тәэмин ителгән:

| Уку еллары | Педагогик кадрлар | Белеме | | | Категорияләре | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | махсус урта | бакалавр | югары | СЗД | I | югары |
| 2018 - 2019 | 15 | 3 | 1 | 11 | 3 | 10 | - |
| 2019 - 2020 | 15 | 2 | 1 | 12 | 3 | 11 | - |
| 2020 - 2021 | 15 | 2 | 1 | 12 | 1 | 13 | - |

Шулардан тәрбиячеләр – 8,
өлкән тәрбияче – 1,
музыка җитәкчесе – 1,
физкультура инструкторы – 1,
рус теле тәрбиячесе – 1,
укытучы - логопед – 1,
педагог – психолог – 1,
чит тел тәрбиячесе – 1.

**Педагогларның белемен һәм квалификациясен күтәрү**

Педагоглар “Электронное образование Республики Татарстан” порталында бирелгән гаризалар нигезендә билгеләнгән вакытта белем күтәрү курсларында белемнәрен күтәрделәр:

| № п/п | Педагогның фамилиясе, исеме | Вазыйфасы | Белем күтәрү курсларында уку вакыты | Белем күтәрү курсларын үткәрү урыны |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Набиева Чулпан Дилбәр кызы | Укытучы-логопед | 05.10.- 16.10. 2020 | АНО ДПО «Академия менеджмента», 72 часа, удостоверение № АМ00394/2020 от 16.10.2020 |
| 2. | Бадертдинова Ирина Ригел кызы | Музыка җитәкчесе | 09.11.- 21.11. 2020 | Приволжский межрегиональ-ный центр повышения квалификации и профессио-нальной пере-подготовки |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | работников образования Института психологии и образования «КФУ», 72 часа, удост. № КФУ 04151/2020, от 21.11 2020 г. |
| 3. | Шакурова Гөлфира Фәрит кызы | Тәрбияче | 01.02.- 11.02. 2021 | АНО ДПО «Академия менеджмента», 72 часа, удост. № АМ 00060/2021 от 11.02.2021 г. |
| 4. | Ганиева Эльвира Илгиз кызы | Тәрбияче | 08.02.- 18.02. 2021 | ЧОУ ВО «Казанский инновационный университет им.В.Г.Тимирясова (ИЭУП)», 72 часа, удост. № КИУ 00026/2021 от 18.02.2021 г. |
| 5. | Садыкова Раилә Ренат кызы | Тәрбияче | 15.02.- 25.02. 2021 | АНО ДПО «Академия менеджмента», 72 часа, удост. № АМ 000 /2021 от 25.03.2021 г. |
| 6. | Ибнеева Раушания Рәзиф кызы | Тәрбияче | 22.03.- 09.04. 2021 | ФГБОУ ВО «НГПУ», 72 часа, удост. № 2021 , от 09.04.2021 г. |

Педагоглар республика һәм район күләмендә үткәрелгән семинарларда катнаштылар:

| **№ п/п** | **Педагогның фамилиясе, исеме** | **Вазыйфасы** | **Семинарның темасы** | **Үткәрү урыны** |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Арсланова Г.М. | Тәрбияче | Республиканские педагогические чтения “Развитие фамилистического мышления и поведения дошкольников в процессе реализации программы “Семьеведение” | Казан |
| 2. | Ардуанова Г.Т. | Тәрбияче | | Актаныш |
| 3. | Габдрахманова Э.Р. | Тәрбияче | “Инновационные формы работы семьей в условиях | Яр Чаллы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | реализации ФГОС” | |
| 4. | Ганиева Э.И. | Тәрбияче | “Педагогическое проектирование в контексте инновационной образовательной деятельности. Детский сад и семья: связанные одной целью” | Актаныш (Казан) |
| 5. | Ибнеева Р.Р. | Тәрбияче | “Педагогическое проектирование в контексте инновационной образовательной деятельности. Детский сад и семья: связанные одной целью” | Актаныш (Казан) |

Тәрбиячеләр Габдрахманова Э.Р., Шаяхметова Г.Ф. тәрбиячеләрнең район методик берләшмәсе утырышларында, тәрбиячеләр Мансурова Э.Р., укытучы-логопед Набиева Ч.Д. район тәрбиячелә-ренең рус теленә өйрәтү буенча методик берләшмәсе утырышларында катнашып үзләренең белем-нәрен күтәрделәр, педагогик осталыкларын арттырдылар.

**Педагогик тәҗрибәне тарату.**

Балалар бакчасы базасында үткәрелгән “Балаларны туган теле һәм рус теленә өйрәтү буенча бе-лем бирү эшчәнлекләрендә матур әдәбият белән таныштыру” темасына район балалар бакчалары тәрбиячеләренең ана теле һәм рус теленә өйрәтү буенча методик берләшмәсе утырышында тәрбия-челәр:

Ибнеева Р.Р.- беренче кечкенәләр төркемендә “Ә.Каринең “Тавык” шигырен уку” темасына сөйләм үстерү буенча белем бирү эшчәнлеге,

Ардуанова Г.Т.- зурлар төркемендә “Кырлайга сәяхәт” темасына сөйләм үстерү буенча белем бирү эшчәнлеге,

Мансурова Э.Р.- мәктәпкә әзерлек төркемендә “Кырлайга сәяхәт” темасына рус теленә өйрәтү буенча белем бирү эшчәнлеге,

Ганиева Э.И.- мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән “Туган телем - иркә гөлем” темасына күнел ачу,

Габдрахманова Э.Р., Садыкова Р.Р. мастер-класс үткәреп, үзләренең эш тәҗрибәләре белән ур-таклаштылар.

Тәрбиячеләр Арсланова Г.М., Ибнеева Р.Р., өл.тәрбияче Гумерова Л.М. басмача эзерләгән эш-кәртмәләрен тараттылар.

Тәрбиячеләр Ардуанова Г.Т., Габдрахманова Э.Р. район педагогларның август конференциясе-нең б/бакчалары тәрбиячеләре секция утырышында чыгыш ясап, үзенең эш тәҗрибәләре белән ур-таклаштылар.

Тәрбиячеләр үзләренең эш тәҗрибәләрен балалар бакчасының интернеттагы сайтына һәм башка педагогик сайтларга (“Ncportal”, “Копилка уроков”) да урнаштырдылар, “Ачык дәрес” газетасын-да бастырдылар.

**Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту**

Балалар бакчасының санитар-гигиеник торышы тиешле таләпләргә туры килә. 2020-2021 нче уку елында балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, физик һәм психик үсешләрен тәэмин итү, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыру буенча системалы эш алып барылды. Балалар бакчасында һава, яктылык, балалар-ның туклану режимнары нормада

сакланды. Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен профилактик чаралар даими үткәрелде:

- бүлмәләрне җилләтү;
- һава торышына карап балаларны иртән кабул итүне һәм кич озатуны саф һавада үткәрү, прогулканың вакытын саклау;
- балаланың сезонга карата киенүләрен булдыру;
- иртәнге гимнастика, физик үсеш шөгыльләрендә балаларны җиңеләйтелгән киемнәрдән йөртү;
- һава торышына карап иртәнге гимнастика, физик үсеш шөгыльләрен саф һава-да үткәрү;
- кояш һәм һава ванналары;
- һәр балага Манту пробасын куйдырту;
- ай саен профилактик прививкаларга җибәрү; профилактик прививкалардан соң балаларны 10 көн буена күзәтү;
- әти-әниләр ризалыгы белән балаларга грippка каршы прививка ясату;
- җиләк-җимешләр, соклар бирү, суган, сарымсак куллану; менюдагы 3 нче блюдоны витаминлаштыру.

Шулай ук балаларның сәламәтлегенең торышын ачыклау өчен медицина тикше-рүе үткәрү, лаборатор тикшерүләр үткәрү (төрле вак кортларга тикшертү), махсус специалистларга җибәрү кебек чаралар план буенча оештырылды.

Балалар белән сәламәтләндерү чаралары системалы үткәрелде:

- чыныктыру (яланаяк йөрү, һава ванналары, аякка су кою; группа бүлмәсендә һәм участокта "сәламәтлек сукмагы"нан йөрү; көндезге аштан соң тамак һәм авыз куышлыгын су белән чайкату);
- яз һәм көз кул чукларын кварцлау;
- сулыш күнегүләре;
- уртанчылар, зурлар, мәктәпкә әзерлек А, мәктәпкә әзерлек Б төркемнәре бала-лары белән яссытабанлылыкка каршы гимнастика;
- Су Джок массажы;
- Чижевский люстралары куллану;
- физотерапия дәвалау курслары табиб күрсәтмәләре буенча 135 (80 балага) үткәрелде: дару үләннәре белән ингаляцияләр - 33,
- күкрәк читлегенә кварц кую - 34,
- борын-тамакка УФО кую - 68.

Бу юнәлештә педагоглар һәм әти-әниләр белән консультацияләр:"Балаларны сәламәтләндерүдә прогулканың әһәмияте","Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның тор-мышында режимның әһәмияте", һәр төркемнең ата-аналар җыелышында табиб һәм медицина хезмәткәре белән "Хәзерге заманда йогышлы авырулар. Прививка-ларның турында без нәрсәләр белергә тиеш?" темасына очырашулар үткәрелде, ата-аналар алдында чыгышлар ясалды, күрсәтмә информация эшләнде: "Балаларда сулыш юлы авыруларына профилактика", "Грипп", "Сак булыгыз, котыру чире", балалар бакчасы сайтына мәгълүмәт куелды.

Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру өчен физик үсеш чаралары да кулланылды. Бу юнәлештә эшнең эчтәлеге "Физик үсеш" белем бирү өлкәсендәге эшчәнлек турында бүлектә бирелә.

**Балаларның туклануын оештыру**

Балаларның сәламәтлеге, алар организмының авыруларга каршы торучанлыгы туклану сыйфатына да бәйле. 2017-2018 нче уку елында балалар бакчасында бала-лар туклануында төп продуктлар буенча норма 100 % үтәлде.

Балалар бакчасында балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен уңай шартлар булдырылган һәм бу юнәлештә эшчәнлек алып барыла. 1 балага авыру бу-енча калдырган көннәр күрсәткече артмаган, травматизм очраклары юк. Ләкин балалар бакчасына килүче балаларның сәламәтлеге елдан-ел начарлана баруын һәм диспансеризация үткәндә ачыкланган авыруларны билгеләп үтәргә кирәк. Шуңа да сәламәт бала тәрбияләүдә әти-әниләр белән тыгыз эшчәнлек алып бару зарур. Шулай ук төрле белем бирү эшчәнлекләрдә сәламәтләндерү технологияләрен кулла-ну, балаларда сәламәт яшәү рәвеше турында күзаллауларын булдыру, сәламәт-ләндерү һәм чыныктыру чараларын кулланганда һәр балага аерым якын килүгә игътибар итәсе бар. Һәм бу чараларны тормышка ашырганда медицина персона-лының игътибарын һәм контролен көчәйтергә кирәк.

**Балалар бакчасының белем бирү программасының үтәлеше**

Уку елы дәвамында балалар бакчасында балаларның үсеш юнәлешләре буенча белем һәм тәрбия бирү бурычларын тормышка ашыру өстендә эш алып барылды.

**<u>“Социаль-аралашу үсеше” белем бирү өлкәсендә эшчәнлек</u>**

Балаларда әхлак сыйфатларын тәрбияләү, җәмгыяттә кабул ителгән нормаларны үзләштерү, көнкүрештә, җәмгыяттә, табигатьтә үз-үзеңне тоту, яшьтәшләре һәм зурлар белән аралашу нигезләренә өйрәтү Закирова К.В.“Гаилә һәм балалар бакчаларында әдәплелек тәрбияләү программасы”на, “Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларны юлларда үз-үзеңне хәвефсез тоту кагыйдәләренә өйрәтү” программасына нигезләнеп, төрле эшчәнлекләрдә: белем бирү эшчәнлекләре, сюжетлы-рольле уеннарда, экскурсияләр, сәнгать эшчәнлеге, театр эшчәнле-ге, уеннарда, күнел ачулар, бәйрәмнәрдә алып барылды.

Балаларда хезмәткә уңай караш тәрбияләү, зурларның хезмәте турында күзаллауларын булдыру максатыннан район янгын бүлегенә, балалар китапханәсенә, кибеткә экскурсияләр оештырылды.

Балаларны юл хәрәкәте куркынычсызлыгы кагыйдәләренә өйрәтү буенча “Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы” атналыгында балалар һәм әти-әниләр белән төрле чаралар: белем бирү эшчәнлекләре, күңел ачулар, КВНнар, тематик кичәләр, Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы фонды хезмәткәре белән очырашу үткәреледе. Район мәдәният йортында Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы фонды оештырган курчак театры тамашасын да балалар яратып кабул итте. Тәрбиячеләр ачык чаралар күрсәтеп үзләренең эш тәҗрибәсе белән уртаклаштылар. Әти-әниләр өчен шулай ук күрсәтмә мәгълүмат эшләп куелды: ширмалар, памяткалар, стена газеталары.

Әти-әниләр белән берлектә балаларның тормыш куркынычсызлыгы кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, аларны тормышта куллану буенча эшчәнлекне көчәйтергә, балаларда әхлак сыйфатларын тәрбияләү, җәмгыяттә кабул ителгән нормаларны үзләштерүгә һәм үтәргә өйрәтү эшчәнлеген дәвам итәргә кирәк.

**“Танып белү” белем бирү өлкәсендә эшчәнлек**

Балаларның элементар математик күзаллауны формалаштыру буенча эш икенче кечкенәләр, уртанчылар, зурлар, мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә белем бирү эшчәнлекләрендә һәм режимның төрле вакытларында Помораеваның “Формирование элементарных математических представлений”, Новикова В.П.ның “Математика в детском саду” методик эшкәртмәләре буенча, Петерсон Л.Г., Холина М.ның “Раз ступенька, два ступенька...” (“Школа – 2000...) методик ярдәмлеге буенча алып барылды. Балаларга ныклы белем һәм тәрбия бирергә, белемнәрен тирәнәйтергә, практик күнекмәләр формалаштырырга, күзаллауларын киңәйтергә һәм иҗади сәләтләрен үстерүдә ТРИЗ алымнары, проблемалы өйрәтү, үстерешле уеннар, ИКТ кулланылды.

Балаларның программаны үзләштерү күрсәткечләре түбәндәгечә булды:

| Уку еллары | Балалар саны | Югары | Уртача | Түбән |
|---|---|---|---|---|
| 2018 – 2019 | 143 | 52 % | 48 % | - |
| 2019 – 2020 | 141 | 50 % | 50 % | - |
| 2020 – 2021 | 147 | 51 % | 49 % | - |

Балаларны предметлы тирәлек, әйләнә-тирә социаль дөнья һәм табигать дөньясы белән таныштыру төрле эшчәнлекләрдә сүзле, күрсәтмәле, уен алымнары, экспериментлар, информацион-коммуникатив, проект технологияләре кулланып алып барылды. Балалар белән балалар бакчасы территориясендә күзәтүләр һәм экскурсияләр, район балалар китапханәсенә, район мәдәният йортына, Балалар иҗат үзәгенә, үзәк стадионга,“Туган як музее”на, Актанышыбызның паркларына (Мәдәният паркы, Җиңү паркы, “Актаныш басмалары” паркы), Бүләк урманына экскурсияләр оештырылды.

Балаларның танып-белү эшчәнлегенә кызыксынуларын арттыру, яңа ачышлар ясарга этәрү өчен проблемалы өйрәтүне, экспериментларны, информацион-коммуникатив технологияләрне киңрәк кулланып эшләү кирәк.

**“Сөйләм үсеше” белем бирү өлкәсендә эшчәнлек**

Балаларның сөйләм телен үстерү эше балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы тәкъдим иткән “Туган телдә сөйләшә-без” укыту-методик комплекты буенча: методик ярдәмлегендә бирелгән планнар, белем бирү эшчәнлеге эшкәртмәләре буенча,“Туган телдә сөйләшәбез” күрсәтмә һәм тарату рәсемнәре комплектын, уеннарын, мультимедиа чараларын кулланып, системалы алып барылды.

Балалар белән курчак театры тамашаларын карау да оештырылды.

Балаларның “Сөйләм үсеше”белем бирү өлкәсендә программаны үзләштерү күрсәткечләре түбәндәгечә булды:

| Уку еллары | Балалар саны | Югары | Уртача | Түбән |
|---|---|---|---|---|
| 2018 – 2019 | 143 | 62 % | 38 % | - |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2019 – 2020 | 141 | 53 % | 46 % | 1 % |
| 2020 - 2021 | 147 | 58 % | 41 % | 1 % |

Бүгенге көндә балалар сөйләменең барлык компонентлары да тиешле дәрәҗәдә үсеш алмый, бигрәк тә авазлар культурасына, сөйләмнең грамматик төзелешенә, бәйләнешле сөйләмгә игътибар итәсе бар. Бу юнәлештә һәр балага индивидуаль якын килеп, эти-әниләр белән берлектә балалар бакчасында да, гаиләдә дә эш алып бару зарур.

**Балаларның сөйләмендә авазларны әйтүдә булган кимчелекләрне төзәтү буен-ча коррекцион эшчәнлек**

2020-21 нче уку елында б/бакчасында логопункт эшләде. Укытучы-логопед Набиева Ч.Д. уку елы башында балаларда сөйләмендә авазларны әйтүдә булган кимчелекләре тикшереп, ел дәвамында әлеге кимчелекләрне төзәтү өстендә эш алып барды. Балалар сөйләмендә авазларны әйтүдә булган кимчелекләре төзәтү өстендә эш укытучы-логопед төзегән логопунктның эш планы һәм эш программасы нигезендә оештырылды. Ел дәвамында логопунктта 10 бала шөгыльләнде. Балалар белән индивидуаль һәм төркемчәләрдә шөгыльләр үткәрелде.

Балаларның сөйләмендә авазларны әйтүдә булган кимчелекләрне төзәтү буенча коррекцион эшчәнлек нәтиҗәләре:

| Уку елы | Логопунктта шөгыльләнүче балалар саны | Мәктәпкә чыгучы балалар | |
|---|---|---|---|
| | | яхшы сөйләм белән | яхшыртылган сөйләм белән |
| 2020 - 2021 | 10 | 9 | 1 |

Тәрбиячеләренең рус теле буенча район методик берләшмәсе утырышы өчен мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән төркемчәдә "Дуслык" темасына укытучы-логопедның эшчәнлеге, эти-әниләр һәм педагоглар өчен балалар белән ачык эшчәнлекләр күрсәтелде. Педагоглар һәм эти-әниләр өчен консультацияләр,"Артикуляцион күнегүләр", "Логоритмик күнегүләр" темаларына практикумнар, җыелышлар үткәрелде.

Сөйләмендә авазларны әйтүдә кимчелекләре булган балаларны ачыклап, кимчелекләрне төзәтү буенча коррекцион эшчәнлекне дәвам итәргә.

**Рус теленә өйрәтү**

Балаларны рус теленә өйрәтү уртанчылар, зурлар, мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә Гафарова С.М., Гарафиева Г.З. "Изучаем русский язык" укыту-методик комплекты буенча оештырылды. Рус теленә өйрәтү укыту-методик комплектының методик ярдәмлегендә бирелгән планнар һәм белем бирү эшчәнлеге эшкәртмәләренә нигезләнеп, уен алымнары һәм уеннар, "Изучаем русский язык" күрсәтмә һәм тарату рәсемнәре комплектын, эш дәфтәрләре, аудио- һәм видео- материаллар, ИКТ кулланып системалы алып барылды. Рус теленә өйрәтү буенча белем бирү эшчәнлекләрендә һәм режимның башка вакытларында да балалар белән төрле эш төрләре үткәрелде: рус телендә әңгәмәләр, шигырьләр, җырлар өйрәнү, сүзле, дидактик, хәрәкәтле, сюжетлы-рольле, җырлы уеннар уйнау, экиятләрне сөйләргә өйрәнү, аларны сәхнәләштерү, аудио-дисклар тыңлау, рус телендә мультфильмнар карау.

Атнаның пәнҗешәмбе көне - Рус теле көнендә балалар өлкәннәр белән һәм үзара рус телендә аралаштылар.

Рус теле атналыгында балалар белән төрле кызыклы чаралар үткәрелде: викторина, КВНнар, әкиятләр сәхнәләштереп күрсәтү, шигырьләр кичәсе.

Балалар белән рус телендә караган мультфильмнар буенча “Минем яраткан мультфильм” темасына рәсемнәр күргәзмәсе оештырылды.

Рус теленәдә өстәмә белем һәм тәрбия бирү буенча “Народные забавы” түгәрәге эшләде (җитәкчесе Мансурова Э.Р.), түгәрәктә 14 бала шөгыльләнделәр.

Балаларның программаны үзләштерү күрсәткечләре түбәндәгечә булды:

| Уку еллары | Балалар саны | Югары | Уртача | Түбән |
|---|---|---|---|---|
| 2018 – 2019 | 143 | 62 % | 38 % | - |
| 2019 – 2020 | 141 | 52 % | 46% | 2 % |
| 2020 – 2021 | 147 | 61 % | 39 % | - |

## “Сәнгати-эстетик үсеш” белем бирү өлкәсендә эшчәнлек

### Сынлы сәнгать эшчәнлеге

Балаларны сынлы сәнгать эшчәнлегендә үстерү аларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, төрле материаллар һәм яңа технологик алымнар кулланып оештырылды. Балаларда әйләнә-тирәдәге предметларга һәм күренешләргә эстетик мөнәсәбәт, сәнгать эшчәнлегенә карата кызыксыну тәрбияләү, иҗади сәләтләрен үстерү өстендә эш алып барылды.

Балаларның “Сәнгати-эстетик үсеш” белем бирү өлкәсендә программаны үзләштерү күрсәткечләре түбәндәгечә булды:

| Уку еллары | Балалар саны | Югары | Уртача | Түбән |
|---|---|---|---|---|
| 2018 – 2019 | 143 | 38 % | 62% | - |
| 2019 – 2020 | 141 | 50 % | 50 % | - |
| 2021 – 2021 | 147 | 59 % | 41 % | - |

### Музыка эшчәнлеге

Балаларны музыка эшчәнлегендә үстерү, белем бирү һәм иҗади сәләтләрен үстерү буенча эш системалы алып барылды. Белем бирү программасы буенча билгеләнгән бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр системалы үткәрелде. Шулай ук Өлкәннәр көне, Әниләр көне, Кошлар көне, Җир көне, Г.Тукай көненә карата бәйрәмнәр һәм кичәләр оештырылды. Балалар бакчасында балалар арасында “Созвездие-Йолдыз-лык”- 2021 Республика эстрада сәнгате яшьләр фестиваленең район этабына сайлап алу туры үткәрелде.

Бу юнәлештә балаларга өстәмә белем һәм тәрбия бирү, иҗади сәләтләрен үстерү максатыннан “Бәхетле балачак” вокал түгәрәге эшләде (җитәкчесе Бадертдинова И.Р.), түгәрәктә 12 бала шөгыльләнделәр. Анда балаларны җырларга, биергә өйрәтү, артистлык сыйфатларын үстерү өстендә эш алып барылды.

Балаларның музыка эшчәнлеге буенча программаны үзләштерү күрсәткечләре түбәндәгечә булды:

| Уку еллары | Балалар | Югары | Уртача | Түбән |
|---|---|---|---|---|

| | саны | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2018 – 2019 | 143 | 38 % | 62% | - |
| 2019 – 2020 | 141 | 40 % | 60 % | - |
| 2020 – 2021 | 147 | 60 % | 40 % | - |

**“Физик үсеш” белем бирү өлкәсендә эшчәнлек**

Балаларның физик үсешен тәэмин итү, физик күнекмәләрен камилләштерү һәм хәрәкәт активлыкларын үстерү өчен балалар бакчасында бу юнәлештә белем һәм тәрбия бирү эше балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, режим буенча, төрле эш формалары кулланып үткәрелде: иртәнге гимнастика, бүлмәдә һәм саф һавада физик үсеш шөгыльләре, хәрәкәтле уеннар, төрле эшчәнлекләрдә физкультминутлар, динамик тәнәфесләр, бармаклар гимнастикасы, күзләр өчен гимнастика, йокыдан соң гимнастика, балалар белән индивидуаль эшләр, паркларга, урманга җәяүле поход-прогулкалар, күңел ачулардан тыш “Ватанны саклаучылар көне”, “Нәүрүз”, “Сабантуй” бәйрәмнәрендә хәрәкәтле уеннар һәм ярышлар оештырылды. Һәр атнаның җомга көнендә балалар белән ритмик гимнастика үткәрелде.

Балаларда умыртка баганасы кәкрәюне кисәтү өчен күнегүләр, яссытабанлылыкны кисәтү өчен профилактик күнегүләр комплекслары үткәрелде, “сәламәтлек сукмаклары”, массаж келәмнәре кулланылды.

Балаларга “Физик үсеш” белем бирү өлкәсендә өстәмә белем һәм тәрбия бирү өчен “Ритмик гимнастика” түгәрәге (Сарварова А.Э.җитәкчелегендә) эшләде, анда 15 бала шөгыльләнде. Түгәрәктә өйрәнгән күнегүләрне балалар бәйрәмнәрдә күрсәтеп чыгыш ясадылар.

Балаларның физик күнекмәләренең үсеш күрсәткечләре:

| Уку еллары | Балалар саны | Югары | Уртача | Түбән |
|---|---|---|---|---|
| 2018 – 2019 | 143 | 48 % | 52 % | - |
| 2019 – 2020 | 141 | 66 % | 34 % | - |
| 2020 – 2021 | 147 | 60 % | 40 % | - |

Балалар бакчасының педагоглары һәм башка эшче-хезмәткәрләре арасында да сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча эш оештырылды. Эшче-хезмәткәрләр районда үткәрелгән спорт чараларында актив катнаштылар.

Бүгенге көндә кешеләрдә транспорт чаралары арту, балаларның төрле гаджетлар белән мавыгуы аркасында хәрәкәт активлыгы кимеде. Шуңа күрә балаларда хәрәкәтләнү теләге булдыру, төп физик сыйфатларны үстерү, организмны чыныктыруга игътибарны көчәйтергә, сәламәт яшәү рәвеше турында күзаллауларын булдыру өстендә эшләргә кирәк.

**Балаларны мәктәпкә әзерләү**

Балаларга тәрбия һәм белем бирү эшендә балалар бакчасы һәм мәктәп арасындагы бәйләнешне үстерү максатыннан эш алып барылды: мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән Актанышның 1нче һәм 2нче мәктәпләренә экскурсияләр, әңгәмәләр оештырылды, әти-әниләр өчен консультацияләр, әңгәмәләр, ачык чаралар үткәрелде, курсәтмә материаллар:“Баланы

мәктәпкә әзерләү” стенды, ширмалар куелды. Район балалар бакча-ларының өлкән тәрбиячеләреннән торган комиссия өчен мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән йомгаклау белем бирү эшчәнлекләре күрсәтелде.

Мәктәпкә әзерлек төркемнәре балаларының мәктәпкә әзерлеген тикшерү нәтиҗәләре:

| **Әзерлек дәрәҗәсе** | **2020 - 2021 нче уку елы** |
|---|---|
| Югары | 60 % |
| Уртача | 40 % |

2020-21 нче уку елында балалар бакчасы коллективы “Балалар бакчасында һәр балага сыйфатлы мәктәпкәчә белем алуда тигез мөмкинлекләр тәэмин итү максатыннан, балалар бакчасының эшчәнлеген мәктәпкәчә белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандартына туры китереп оештыру” максаты буенча түбәндәге бурычлар өстендә эшләде:

1. Педагогларның тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегендә мәктәпкәчә белем бирүнең ФДББ стандартын тормышка ашыру буенча практик эш тәҗрибәләрен камилләштерү.

2. Балаларның танып-белү сәләтләрен формалаштыруда үстерешле уеннарны куллану.

3. Мәктәпкәчә белем бирүнең ФДББ стандарты буенча балаларга тәрбия һәм белем бирүдә бердәм эшчәнлек булдыруда гаиләләр белән багланыш модельләрен камилләштерү.

Куелган бурычларны тормышка ашыру максатыннан тәрбиячеләр белән “Сәнгати-эстетик үсеш” белем бирү өлкәсендә мәктәпкәчә белем бирүнең ФДББ стандартын тормышка ашыру”, “Балаларның танып-белү сәләтләрен формалаштыруда үстерешле уеннарны куллану” темаларына педагогик киңәшмәләр, “Төркемнәрдә балаларның сәнгати-эстетик эшчәнлектә үсеше өчен шартлар булдыру” темаларына тикшерүләр, мәктәпкә әзерлек төркемендә балаларның мәктәпкә әзерлеген тикшерү үткәрелде. “Балалар бакчасында балаларны сәламәтләндерү чараларын куллану”,“Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда матур әдәбияткә карата кызыксыну һәм ярату тәрбияләү буенча эшне оештыру”,“Балалар бакчасында ком терапиясе, аның мөмкинлекләре” темаларына семинарларда, “Продуктив эшчәнлек аша балаларны халык декоратив - гамәли сәнгате белән таныштыру” темасына семинар-практикумда, коллектив күзәтү өчен икенче кечкенәләр, уртанчылар, зурлар төркемнәрендә балаларда матур әдәбияткә карата кызыксыну һәм ярату тәрбияләү буенча ачык чараларны коллектив күзәтү, балаларны халык декоратив - гамәли сәнгате әсәрләре бизәкләрен сүрәтләү алымнарына өйрәтү буенча мастер-класслар, “Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы” атналыгында юл хәрәкәте куркынычсызлыгы кагыйдәләренә өйрәтү буенча икенче кечкенәләр, уртанчылар, зурлар, мәктәпкә әзерлек төркемендә ачык чаралар күрсәтеп, тәрбиячеләр үзләренең белемнәрен күтәрделәр, педагогик осталыкларын арттырдылар, эш тәҗрибәләре белән уртаклаштылар.

Балалар бакчасында педагоглар арасында “Яңа уку елына әзерлек – 2020” конкурсы үткәрелде, төркем бүлмәләрендә Иҗат итү үзәкләренә күргәзмә оештырылды.

“Ел тәрбиячесе – 2021” район конкурсларында катнашу өчен, әзерләгән портфолиоларны карап, педагог Бадертдинова И.Р. сайлап алынды.

**<u>Ата-аналар белән эш</u>**

Балалар бакчасы һәм гаиләнең бәйләнешен үстерү, бердәм эшчәнлеген булдыру максатыннан әти-әниләр белән гомуми һәм группа җыелышлары, “Бала һәм хәзерге заман техникасы һәм гаджетлар” темасына җыелыш үткәрелде. Район үзәк хастәханәсе табибы һәм белгече, Юл хәрәкәте иминлеге фонды хезмәткәре белән, балалар бакчасының педагог-

специалистлары: физкультура инструкторы, укытучы-логопед белән очырашулар үткәрелде, аларның чыгышлары, киңәшләре тыңланды. Әти-әниләр бәйрәмнәргә күңел ачуларга, ачык чараларга чакырылды, балалар белән спорт ярышларында, экскурсияләрдә катнаштылар. Гаилә көненә карата "Гаилә белән спортны яратабыз" темасына беренче кечкенәләр төркеме әти-әниләре һәм балалары белән кичә үткәрелде.

Шулай ук әти-әниләр өчен төрле темаларга күрсәтмә материаллар: стендлар, ширмалар, группа папкалары эшләнеп, даими үзгәртеп торылды. "Минем яраткан китабым" конкурсы (әти-әниләр һәм балалар өчен) үткәрелде. "Көзге вернисаж" темасына әти-әниләр һәм балаларның бергәләп табигый материаллардан эшләгән эшләренән, "Яңа ел могҗизалары" темасына төрле материаллардан эшләгән яңа ел уенчыкларыннан, "Әниемә бүләк" балалар эшләреннән, "Әтиемнең оста куллары" темасына күргәзмәләр, "Безнең яраткан балалар бакчасы" темаларына фотокүргәзмә оештырылды.

## Административ – хуҗалык эше

Балалар бакчасының материаль-техник базасы канәгатьләнерлек. Барлык бүлмәләр дә дәүләт нормаларына һәм санитар-гигиеник таләпләргә туры китереп җиһазланган. Төркем бүлмәләрендә һәм кабинетларда балаларның яшь үзенчәлекләренә туры китереп үстерешле предметлы-пространство тирәлекләре җиһазланган. Бу уку елында балалар бакчасы ТР балалар бакчаларын капталь төзекләндерү дәүләт программасына кертелде һәм 2018 елда балалар бакчасында капиталь төзекләндерү эшләре башкарылды. Төзекләндерү белән бергә балалар бакчасының материаль- техник базасын яңарту: яңа җиһазлар кайтарту, уен мәйданчыкларында яңа кече уен формалары куйдырту, үстерешле предметлы-пространство тирәлеге өчен яңа җиһазлар һәм материаллар булдыру өстендә эш алып барыла. Кирәкле җиһазлар, уен формалары һәм материалларның исемлеге төзелде.

## Нәтиҗәләр

Балаларның белем бирү өлкәләрендә үсешен, педагогларның эшчәнлеген уңай һәм балалар бакчасының ел дәвамында эшчәнлеген канәгатьләнерлек, дип билгеләргә.

# II ЭШ ПЛАНЫ

## 2.1 Яңа 2021-2022 уку елына куелган бурычлар, проблемалар һәм перспективалар

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Актаныш гомуми үсеш бирүче №4 балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә 2021-2022 нче уку елында барысы гомуми үсеш бирүче төрдәге 6 төркем эшлиячәк. Балалар төркемнәргә яшьләре буенча түбәндәгечә бүленәләр:

| | | |
|---|---|---|
| Ясле төркеме | 1 яшьтән 2 яшькә кадәр | 16 бала |
| 1 кечкенәләр төркеме | 2 яшьтән 3 яшькә кадәр | 22 бала |
| 2 кечкенәләр төркеме | 3 яшьтән 4 яшькә кадәр | 19 бала |
| Уртанчылар төркеме | 4 яшьтән 5 яшькә кадәр | 27 бала |
| Зурлар төркеме | 5 яшьтән 6 яшькә кадәр | 26 бала |
| Мәктәпкә әзерлек төркеме | 6 яшьтән 7 яшькә кадәр | 21 бала |

Милләтләре буенча күпчелек бала татарлар. Тәрбия һәм белем бирү татар телендә алып барыла.

Балаларга белем һәм тәрбия бирү буенча эшчәнлек «Актаныш гомуми үсеш бирүче 4нче балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең белем бирү программасы нигезендә оештырыла.

### 2.1.1 Максат, бурычлар

